Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче
Троицкий Урай авылы торак пунктында узган
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 1 ноябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай авылы торак пунктында узган гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп (көндезге бүлектә) укучы студентлардан гайре, 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

- Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче торак пунктлары чикләрендә юлларны карап торуга һәм ремонтлауга;
- Троицкий Урай авыл җирлеге торак пунктларындагы православие зиратын төзекләндерүгә;
- 4 данә евроконтейнер сатып алуга һәм Гремячка авылында контейнер мәйданчыгына козырек урнаштыруга;
- энергия саклаучы лампалар сатып алуга һәм авыл җирлеге торак пунктында урнаштыруга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Троицкий Урай авылы Прикамская урамы, 9 йорт; Гремячка авылы Александров урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Троицкий Урай авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сафин